**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 июнендәге 1706 номерлы карары**

**Киров районының Аркылы Гривка урамындагы**
**территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, А.Г.Шошокин гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьяларына, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану турында»гы федераль законның 8 статьясына таянып, Казан шәһәре Вахитов районы судының 2а-5832/2024 номерлы эш буенча законлы көченә кергән 2024 елның 23 сентябрендәге карарын, 2025 елның 6 мартыннан 2025 елның 20 мартына кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, проект документациясен эшләүгә 2023 елның 29 ноябрендәге 00БП-007340 номерлы шартнамәне исәпкә алып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Киров районының Аркылы Гривка урамындагы территорияне ызанлау проектын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга;

1.2. әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, транзит инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга;

1.3. әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы

нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, транзит инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.4. әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына (Р.Г.Галәветдинов) 2023 елның 25 декабрендәге 2847/КЗИО-ПК номерлы «Объект урнаштыру өчен җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт турында»гы әмерне гамәлдән чыгарырга.

2. Гражданин А.Г.Шошокинга **тәкъдим итәм**:

2.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру зоналары картасына шәхси һәм блоклап төзелгән торак төзелеше территориаль зонасы (Ж1) һәм катлар саны уртача булган торак төзелеше территориаль зонасы (Ж3) чикләре белән кисешүне булдырмау өлешендә үзгәрешләр кертү өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе каршындагы Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә кую өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.3. җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, җир кишәрлеген әлеге карарга кушымта нигезендә яңадан бүлү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына тиешле документларны тапшырырга;

2.4. әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлегенең кадастр номеры турында мәгълүмат тапшырырга;

2.5. җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда:

2.5.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмаларның аларга тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

2.5.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка **йөклим**.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 июнендәге
1706 номерлы карары белән
расланды

**Киров районының Аркылы Гривка урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге, транзит инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге, транзит инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырып чыгарылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Проектлана торган территория Казан шәһәре Киров районының Аркылы Гривка урамында урнашкан.

Әлеге территория өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 14 мартындагы 943 номерлы карары белән расланган Мулланур Вахитов,

Яруллин, Пролетар һәм Бугринская урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты эшләнде.

Территорияне ызанлау проекты территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, Аркылы Гривка урамында төзелгән территориядә кызыл линияләр урнаштыру һәм җир ашалыкны бетерү максатыннан әзерләнде.

Территорияне ызанлау проекты белән, формалашкан төзелеш шартларында капиталь төзелеш объектын кызыл линияләр чикләреннән төшереп калдыру максатыннан, гамәлдәге капиталь төзелеш объекты чиге буйлап билгеләнгән кызыл линияләргә төзәтмәләр кертелә. Кызыл линияләр, гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын исәпкә алып, гомуми файдаланудагы территориянең чикләрен аныклау максатыннан билгеләнә.

Кызыл линияләр, шәһәр төзелеше шартларын исәпкә алып, Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларының төп параметрлары нигезендә фактта формалашкан җирдән файдалану нигезендә билгеләнә.

Әлеге ызанлау проектында, хосусый милектәге 16:50:090701:2121 кадастр номерлы җир кишәрлеген һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлеп, «:ЗУ1» шартлы билгесе белән 1 (бер) җир кишәрлеге төзү каралган. Аныклана торган җир кишәрлеге чикләренең фактта урнашу урынын раслау өчен инвентаризация материаллары файдаланылды. Инвентаризация материаллары буенча аныклана торган җир кишәрлеге чикләре әлеге җирлектә 15 елдан артык гамәлдә (Җир төзелеше эше, 2005 ел, №1135).

Ясала торган җир кишәрлеге турында мәгълүмат таблицада китерелгән.

| Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе | Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м | Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 536 | 16:50:090701:2121 | Шәхси торак төзелеше |

Беренчел җир кишәрлегенең чикләре төгәлләштерелгән, хосусый милек хокукы теркәлгән.

Беренчел җир кишәрлеге чикләрендә 16:50:090701:190 кадастр номерлы капиталь төзелеш объекты (торак йорт) урнашкан, ул гариза бирүченең шәхси милкендә.

Ясала торган «:ЗУ1» җир кишәрлеге ике территориаль зонада урнашкан: Ж1 – шәхси һәм блоклап төзелгән торак төзелеше зонасы һәм Ж3 – катлар саны уртача булган торак төзелеше зонасы. Әлеге җир кишәрлеге Казан шәһәре

Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең территориаль зоналарның һәм (яки) ярдәмче зоналарның расланган чикләре белән кисешүен булдырмау максатыннан территориаль зоналар һәм (яки) ярдәмче зоналар чикләренә төзәтмәләр кертү, шулай ук расланган территорияне планлаштыру проектына һәм территориаль зоналарның һәм (яки) ярдәмче зоналарның шәһәр төзелеше регламентына туры килүе өлешендә үзгәрешләр кертелгәннән соң ясалырга мөмкин.

Ясала торган җир кишәрлегенең иң чик минималь һәм максималь зурлыгы Кагыйдәләр нигезендә билгеләнгән.

Кагыйдәләр нигезендә ясала торган җир кишәрлеге шәхси һәм блоклап төзелгән торак төзелеше территориаль зонасында (Ж1) урнашкан. Кагыйдәләрнең 24 статьясының 7 пункты нигезендә җир кишәрлекләрен һәм (яки) җирләрне яңадан бүлгәндә, җир кишәрлекләренең минималь зурлыгы кулланылмый; «шәхси торак төзелеше өчен» Ж1 территориаль зонасында кишәрлекнең максималь зурлыгы билгеләнмәгән.

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан кала, җир кишәрлекләрен бүлгәндә, берләштергәндә, яңадан бүлгәндә яки бүлеп чыгарганда барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану төре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану төре булып таныла. Ясала торган җир кишәрлегенә 16:50:090701:2121 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнә.

Ачык кадастр картасы буенча җир кишәрлеге «Казан – Борисоглебский» эксперименталь авиация аэродромының аэродром яны территориясенең 3, 4 номерлы зоналарында урнашкан.

Ясалган җир кишәрлеге түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, эксплуатацияләүче оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.

Ызанлау проекты территориясе буенча инженерлык коммуникацияләре уза. Транзит инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләре әлеге проектта китерелде.

## II. Территорияне ызанлау сызымы




| Шартлы билгеләр | |
|---|---|
| | ызанлау проекты чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләре |
| | гамәлдәге җир кишәрлеге чикләре |
| :ЗУ1 | ясала торган җир кишәрлеге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләре |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| к1 | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| н1 | ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы ноктасы |
| 1 | территорияне ызанлау проекты чикләренең характерлы ноктасы |
| 16:50:090701:2121 | беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | беренчел җир кишәрлегенең билгеләнеше |
| | элемтә линияләренең сак зоналары чикләре |
| | су чыгаруның сак зоналары чикләре |
| | газүткәргечнең сак зоналары чикләре |
| | транзит коммуникацияләрнең планлаштырыла торган ачык сервитуты |